СОВЕТ КОСТЕНЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОСТЕНЕЕВО АВЫЛ

ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ с. Костенеево КАРАР

№ 138 «23» октября 2024 г.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Костенеевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Костенеевка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 14.12.2018 елның 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Костенеевка авыл җирлеге Советы

Карар кылдым:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Костенеевка авыл җирлеге Советының 14.12.2018 no 150 карары белән расланган» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Костенеевка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларның дәвамлылыгы мондый проект басылып чыккан көннән алып бер айдан да артмый.».

1.2. 13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гавами тыңлауларны уздыру срогы муниципаль берәмлек халкына аларны уздыру турында хәбәр иткән көннән алып гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр ундүрт көннән кимрәк һәм утыз көннән артык була алмый.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис М.С. Данилова